РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

423303, Азнакаевский район, с. Агерзе, ул.Г.Ахметовой, д.14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Әгерже авыл җирлеге башкарма комитеты

423303, Азнакай районы, Әгерже авылы, Г.Ахметова урамы, 14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 15» ноябрь 2019 ел № 14

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.02.2019 ел № 1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында» 26.07.2009 ел № 226-ФЗ Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясы, «Федераль мәгълүмати адреслы система турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 26.07.2019 ел № 227-ФЗ нигезендә Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.02.2019 ел № 1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерже авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: ышанычнамә таныклыгы (№12 кушымта);».

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1.15 пункт белән тулыландырырга:

«1.15. Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читләштерүгә, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (№15 кушымта).»

1.3. Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

1.4. 12 нче кушымтаны әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.5. 2 нче кушымта нигезендә кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http/ / aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Н.Н.Хәсәнов